2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман- Кәләй авылы җирлеге Колшәрип тимер юл станциясе бистәсе гражданнарның үзара салымын кертү турында

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

6 декабрь 2023 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман- Кәләй авыл җирлегенең Колшәрип поселогы гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман- Кәләй авыл җирлегенең Колшәрип тимер юл станциясе бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Колшәрип тимер юл станциясе бистәсе, Железнодорожная урамы, территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урман- Кәләй авыл җирлеге башлыгы Л.Н. Фәләхиев